# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**“15” ноябрь 2024 ел, № 25**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Югары Пошалым авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Югары Пошалым авылында гражданнар җыенының 2024 елның 15 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Югары Пошалым авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту җайланмасы (урам яктырткычлары сатып алу);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Мичурин урамыннан пожарга каршы сусаклагычка таба юл салу; әһәмияттәге юлларның буйга профилен төзәтү; торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Сәләхова урамындагы агачны санитар кисү һәм территориядән чыгару; МТЗ - 82 өчен чапкыч-мульчер сатып алуны өлешчә финанслашу);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Тукай һәм Урал урамнары арасында җәяүле күперен ремонтлау)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

« ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

Халык җыены нәтиҗәләре беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 209 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 111 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 111 кеше

тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Югары Пошалым авылында халык җыены булып узган, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2.Халык җыены нәтиҗәләре соравын кабул итәргә:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Югары Пошалым авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итүһәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту җайланмасы (урам яктырткычлары сатып алу);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Мичурин урамыннан пожарга каршы сусаклагычка таба юл салу; әһәмияттәге юлларның буйга профилен төзәтү; торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Сәләхова урамындагы агачны санитар кисү һәм территориядән чыгару; МТЗ - 82 өчен чапкыч-мульчер сатып алуны өлешчә финанслашу);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Тукай һәм Урал урамнары арасында җәяүле күперен ремонтлау)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга, карар кабул ителгән дип танырга».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Арча районы, Югары Пошалым авылы, Сәләхова урамы, 23 нчы йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan. ru веб-адреслары буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков